СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«_12_» _декабрь_ 2025 ел** **№ _23_**

**Арча район Советының “Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм муниципаль учреждениеләрнең аерым хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында” 2024 елның 22 маендагы 283 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2024 елның 8 ноябрендәге 303 номерлы, 2025 елның 25 апрелендәге 334 номерлы, 2025 елның 15 октябрендәге 10 номерлы үзгәрешәр белән)**

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында” 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында” 2025 елның 25 ноябрендәге 966 номерлы карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставы нигезендә Арча район Советы **карар кылды**:

1. Арча район Советының “Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм муниципаль учреждениеләрнең аерым хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү күләмнәре һәм шартлары турында” 2024 елның 22 маендагы 283 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү турындагы Нигезләмәнең 2 пунктын (1 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затның хезмәте өчен түләү акчалата бүләкләү рәвешендә башкарыла.

| Вазыйфа исеме | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| Арча муниципаль районы башлыгы | 44 814 |
| Арча муниципаль район башлыгы урынбасары | 40 334 |
| Арча муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе | 40 334 |
| Арча муниципаль районы Контроль-хисап палатасы аудиторы | 30 809 |

2) Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль берәмлекләрендә затларның, муниципаль хезмәт урынбасарларының хезмәтенә түләү турындагы нигезләмәнең 3 пунктында (2 нче кушымта) "15 389 сум" сүзләрен "16 928 сум" сүзләренә алмаштырырга.

3) Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турындагы Нигезләмәнең 2 пунктында (3 нче кушымта) "15 389 сум" сүзләрен "16 928 сум" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен һәм җирле үзидарәне саклау буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
Арча район Советы рәисе урынбасары Р.Д.Мөхәммәдияров